ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# "Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында" Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында" 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 2 өлешенә (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

"5) әлеге Законның 9 статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләр булган.".

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

"$2^1$. Граждан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын кардәшлектә яки үги туганлыкта (ата-анасы, ире (хатыны), балалары, абыйлары, апалары, шулай ук ир белән хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары,

балалары һәм балаларның ире яисә хатыны) булса, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларына билгеләп куела алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын били алмый.”.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 16-ТРЗ